РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«15» ноябрь 2018 г. г. Альметьевск № 252

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасында дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә кую, административ хокук бозулар хакында беркетмә төзергә хокуклы вазыйфаи затларның исемлеген билгеләүче вәкаләтле орган турында” 2013 елның 11 мартындагы № 286 карарына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 30 июлендәге “Татарстан Республикасы җирле үзидарә муниципаль берәмлекләренә административ хокук бозулар хакында беркетмә төзергә хокуклы вазыйфаи затларның исемлеген билгеләүче Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләте бирелү турында”гы № 60-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Әлмәт шәһәре прокурорының 2018 елның 28 сентябрендәге №1031п күрсәтмәсен караганан соң,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1.“Татарстан Республикасында дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә кую, административ хокук бозулар хакында беркетмә төзергә хокуклы вазыйфаи затларның исемлеген билгеләүче вәкаләтле орган турында” 2013 елның 11 мартындагы № 286 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

”1.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетын, Татарстан Республикасының административ хокук бозулар турындагы Кодексының 2.1 (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешмаларның аталышы һәм үзе турында мәгълүмат урнаштыруга кагылышлы Татарстан Республикасы телләр турындагы законга карата), 2.4-2.8., 2.12.-2.14., 3.2.-3.8., 3.10 (гражданнарга карата)., 3.11., 3.14.-3.17., 4.4., 5.1., 5.2., 5.6. нчы маддәләрендә каралганча (туры килә торган

Зак. № 2652-100

муниципаль берәмлекләр территорияләрендә гамәлгә ашырылучы муниципаль йөк ташуга карата) Татарстан Республикасында дәүләт вәкаләтен гамәлгә куюю, административ хокук бозулар хакында беркетмә төзергә хокуклы вазыйфаи затларның исемлеген билгеләүче вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

2. 2013 елның 11 мартындагы "Татарстан Республикасында дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә кую, административ хокук бозулар хакында беркетмә төзергә хокуклы вазыйфаи затларның исемлеген билгеләүче вәкаләтле орган турында"гы №286 карарына үзгәрешләр кертү турындагы" 2017 елның 27 декабрендәге №219 Әлмәт муниципаль районы Советы карары үз көчен югалтты дип танырга.

3. Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны "Альметьевский вестник" газетасында бастырып чыгарырга, "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтына урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлүен контрольгә алуны район Советының закон, хокук саклау, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Баһманов И.Р.).

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин